**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**«09» август 2023 ел** **№ 193**

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының 2016 елның 18 апрелендәге 38 номерлы карары белән расланган керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне муниципаль берәмлектә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан бирү хакындагы нигезләмәне үз көчләрен югалткан дип тану турында, шулай ук «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында**

Муниципаль хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 4.2 өлеше һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 8 өлеше, муниципаль берәмлек уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының 2016 елның 18 апрелендәге 38 номерлы карары белән расланган керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр (28.05.2021 № 65, 26.08.2022 № 128 карарлар белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) тапшыру хакында нигезләмәне үз көчләрен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы Рәисе Д.А. Ишкинеев